**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ Х УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 18**

Яңа Усы авылы «20» апрель 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» Яңа Усы авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү турында**

Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 мартындагы 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347 номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 117 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең 2 статьясына түбәндәге эчтәлекле 3 нче пунктны өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.».

2. ««Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 105 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының 2021 елның 7 апрелендәге 17 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы: Г.С.Романова**